КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 21 май г.Казань № б-1018

2026 елның 9 – 11 июнендә Казан шәһәрендә Күмәк иминлек турында шартнамә оешмасы әгъзалары булган дәүләтләрнең тышкы эшләр министрлары советының сессия арасындагы утырышын әзерләгәндә һәм уздырганда федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгатьчелек берләшмәләре хезмәттәшлеген оештыру максатларында:

1. 2026 елның 9 – 11 июнендә Казан шәһәрендә Күмәк иминлек турында шартнамә оешмасы әгъзалары булган дәүләтләрнең тышкы эшләр министрлары советының сессия арасындагы утырышын әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы оештыру комитетын төзергә.

2. Бу боерыкка теркәлгән 2026 елның 9 – 11 июнендә Казан шәһәрендә Күмәк иминлек турында шартнамә оешмасы әгъзалары булган дәүләтләрнең тышкы эшләр министрлары советының сессия арасындагы утырышын әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы оештыру комитеты турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 21 май, б-1018 нче
боерыгы белән расланды

2026 елның 9 – 11 июнендә Казан шәһәрендә Күмәк иминлек турында шартнамә оешмасы әгъзалары булган дәүләтләрнең тышкы эшләр министрлары советының сессия арасындагы утырышын әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы оештыру комитеты турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2026 елның 9 – 11 июнендә Казан шәһәрендә Күмәк иминлек турында шартнамә оешмасы әгъзалары булган дәүләтләрнең тышкы эшләр министрлары советының сессия арасындагы утырышын әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы оештыру комитеты (алга таба шул ук эзлеклелектә – утырыш, Оештыру комитеты) утырышны әзерләгәндә һәм уздырганда федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр хезмәттәшлеген оештыру максатларында төзелгән күмәк орган булып тора.

1.2. Оештыру комитеты үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## 2. Оештыру комитетының төп бурычлары

2.1. Оештыру комитетының төп бурычлары:

утырыш кысаларында үткәрелә торган беркетмә чараларын гамәлгә ашыруны комплекслы координацияләүне гамәлгә ашыру;

утырыш кысаларында уздырыла торган мәдәни-ял программасын һәм рәсми кабул итүне оештыру буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны гамәлгә ашыру;

барлык утырыш уздыру этапларында аккредитация узган массакүләм мәгълүмат чаралары белән нәтиҗәле хезмәттәшлекне оештыру;

тәкъдимнәр әзерләү һәм Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру барышында федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр хезмәттәшлеген оештыру, аларның нәтиҗәлелеген бәяләү.

## 3. Оештыру комитеты хокуклары

3.1. Оештыру комитеты үз алдында торган бурычларны гамәлгә ашыру максатларында түбәндәгеләргә хокуклы:

Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча федераль башкарма хакимият органнарыннан, республика башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм иҗтимагый берләшмәләрдән законнар нигезендә мәгълүмати материаллар соратып алырга;

Оештыру комитеты компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән тәртиптә эшче төркемнәр төзергә;

үз утырышларына федераль башкарма хакимият органнары, республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләрен һәм башка вәкилләрен, башка кызыксынучы затларны билгеләнгән тәртиптә чакырырга;

утырышларны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча киңәшмәләрдә, конференцияләрдә һәм семинарларда катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә.

## 4. Оештыру комитеты составы

4.1. Оештыру комитеты составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4.2. Оештыру комитеты составына Оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм аның эшендә иҗтимагый башлангычларда катнаша торган башка әгъзалары керә.

4.3. Оештыру комитеты рәисе:

Оештыру комитеты эше белән җитәкчелек итә, Оештыру комитеты утырышлары өчен мәсьәләләр исемлеген, аларны карап тикшерү срокларын һәм тәртибен билгели;

Оештыру комитеты әгъзалары арасында вәкаләтләрне (йөкләмәләрне) бүлә;

утырышларның көн тәртибен, аларны үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгели һәм раслый;

Оештыру комитеты утырышлары беркетмәләренә һәм аның башка документларына кул куя.

4.4. Оештыру комитеты рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен Оештыру комитеты рәисе урынбасарларының берсе башкара, ул аның йөкләмәсе буенча Оештыру комитеты утырышын үткәрә һәм Оештыру комитетының утырышлар беркетмәләренә һәм башка документларына кул куя.

4.5. Оештыру комитеты әгъзалары:

Оештыру комитеты утырышларында шәхсән катнаша;

Оештыру комитеты компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне фикер алышуга чыгара;

Оештыру комитеты карарларын әзерләү, үтәү буенча башка чараларны гамәлгә ашыра.

## 5. Оештыру комитеты утырышлары һәм карарлары

5.1. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булуга карап уздырыла.

5.2. Оештыру комитеты утырышларын рәис яисә аның кушуы буенча рәис урынбасарларының берсе алып бара.

5.3. Оештыру комитеты утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала. Оештыру комитеты карары, әгәр аның өчен утырышта катнашкан әгъзаларының кимендә яртысы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Оештыру комитеты утырышының көн тәртибе мәсьәләләрен карап тикшерү һәм тавыш бирү нәтиҗәләре буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә торган карарлар кабул ителә. Оештыру комитеты утырышы беркетмәсе Оештыру комитеты утырышын уздырган көннән алып өч эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

5.4. Оештыру комитеты тарафыннан кабул ителә торган карарлар агымдагы эшчәнлекне гамәлгә ашырганда таянып эш итү өчен кызыксынучы федераль башкарма хакимият органнарына, республика башкарма хакимият органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, башка кызыксынучы затларга җиткерелә.

## 6. Оештыру комитеты эшчәнлеген тәэмин итү

6.1. Оештыру комитеты эшчәнлеген оештыру һәм техник яктан, документлар, мәгълүмат һәм башкалар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 21 май, б-1018 нче
боерыгы белән расланды

2026 елның 9 – 11 июнендә Казан шәһәрендә Күмәк иминлек турында шартнамә оешмасы әгъзалары – дәүләтләренең тышкы эшләр министрлары советының сессия арасындагы утырышын әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы оештыру комитеты
составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Оештыру комитеты рәисе |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Комиссия рәисе урынбасары |
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Насыйбуллин Нәзил Наил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының тышкы икътисадый эшчәнлек буенча ярдәмчесе, Оештыру комитеты сәркатибе |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бакиров Газинур Тәлгать улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Вахитов Радик Рәфикъ улы | Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Воронцов Андрей Юрьевич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча Чик буе идарәсенә караган «Идел буе» чик буе контроле отрядының «Казан-аэропорт» тикшереп үткәрү пункты башлыгы (килешү буенча) |
| Габдрәшитов Булат Рәшит улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт беркетмәсе идарәсе башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гәрәев Марат Мәсгут улы | Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Гомәров Рөстәм Фәрит улы | Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Денисов Максим Сергеевич | «Спорт һәм социаль проектлар дирекциясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Кадамов Ирек Илгиз улы | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Прытков Евгений Александрович | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Романцов Сергей Анатольевич | «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Фәйзрахманов Рушан Васильевич | Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры. |